# Үткәннәрне онытма син!!!

**Һәр нигезнең, һәр авылның,**
**Һәр каланың үткәне бар...**
**Гыйбрәт алырлык мирасның**
**Калганы бар, киткәне бар.**
**Горур сүз әйт, сорасалар:**
**Ни кавемнән? Нинди җирдән?**
**Киләчәккә аек карар**
**Үз тарихын анык белгән!**
**Хәтерләүдән курыкма син!**
**Ил үткәнен онытма син!**

**/Р.Фәйзуллин/**

Сезнең игътибарга Актаныш башлангыч мәктәбе укучылары “Онытма син!” дип аталган проект эшен тәкъдим итә.

Проектыбыз үткән белән бүгенгене берләштерә

# Проектыбызның максаты

- Элекке  һәм хәзерге  авылда архитектура, аларның  төзелеш  үзенчәлекләре
  белән  танышу;

- Халкыбызның  үткәне,  тарихы  белән горурлану

хисләре  тәрбияләү.

.

# Гипотеза

- Һәркайсыбызның матур киенәсе, затлы йортларда яшисе килә. Моңа ирешү өчен сәнгать, сәнгати зәвыклелек ,белем кирәк. Архитектура һәм дизайнның нигезендә менә шулар ята да инде.

# Бурычларыбыз

- Халкыбызда «Үзенең тарихын белмәгән халыкның киләчәге юк» дигән әйтем бар, димәк, без үзебезнең тарихыбызны өйрәнәчәкбез, киләчәгебез турында да кайгыртачакбыз.

# Теманың актуальлелеге:

- Кечкенә ватаның – авылыңның тарихын өйрәнмичә торып, халыкның үткәнен, бигрәк тә аның борынгы чорын нигезле итеп белеп булмый. Ә тарихын белмәгән халык туган төбәген саклау, яшәтү, үстерү юлларын билгели алмый. Тарихны буыннан-буынга җиткерүче, саклаучы төп көч халык үзе булса да, аны билгеле бер нормаларга салып камилләштерү эшен галимнәр башкара. Авыллар тарихын өйрәнүче галимнәр булса да, авылда яшәүче буларак, без туган як тарихын өйрәнүне үзебезнең бурычыбыз итеп саныйбыз.

- Ә хәзер без сезне элеккеге авылда архитектура, аларның төзелеш үзенчәлекләре белән таныштырабыз.

# Йорт

- Элек-электән торак йортлар, нигездә, бүрәнәдән төзелгән, бура **бурап** эшләнгән. Агач һавасы ук икенче булган. Кешеләр табигатькә якын булган. Экологик проблема дигән төшенчәне белмәгәннәр.

# Кое

- Кое элек-электән үзенчәлекле төзелеш. Осталар аның өстенә ике кыеклы түбә ясаган. Кое өйләре аның суын тузаннан , чүп-чар төшүдән саклаган.Шулай ук авыл байларының ишегалдын бизәп тә Бүгенге көндә кое су чыганагы булудан тыш, ландшафт дизайна элементы да булып тора.

# Үрелгән читән койма

- Элек бишекләр дә, каз оялары да талдан үрелеп эшләнгән. Тимер койма дигән нәрсәне белүче дә булмаган, йорт тирәләрен читәннәр бизәгән. Үрелгән читән койма, кое, келәт бу йортка җанлылык өсти. Акрынлап аларны пластик материаллар алыштырды. Читәннәрне этнографик музейларда гына күреп була иде. Ә хәзер халык яңадан экологик чиста продукциягә тартыла башлады. Йорт ишегалларын да талдан үрелгән клумбалар белән бизиләр, читәннәр торгызалар. Бу бигрәк тә үз йортлары белән яшәүче шәһәр халкы арасында популяр.

# Тегермән

- Җил тегермәне белән ашлык тартканнар. Бөртекле ашлыкларны ярма яки он итеп тарттыру өчен корылган җайланма (машина) – төп өлеше бер-берсенә ышкылып әйләнә торган ике таштан тора.  Тегермәнне җил хәрәкәткә китергән.

- Без сезне элеккеге авылда архитектура,

аларның төзелеш үзенчәлекләре белән таныштырдык. Проектның арткы планында хәзерге көн төзелеше. Бу үткән белән бүгенгенең бәйләнешен чагылдыра.

# Йомгаклау

Адәми зат, әгәр үз халкы белән горурланырдай тарихы барын белмәсә, туган туфрагын, милләтен дә танымый башлый. Аның ныклыгын тою өчен төпле терәк кирәк. Тарих, үз халкыңның тарихы-шундый терәк ул. /М.Хәбибуллин/